Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## "Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында" Татарстан Республикасы Законына һәм "Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында" Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында" 2008 елның 22 ноябрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 2; 2011, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:
"4. Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары, аудиторлары вазыйфалары муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән муниципаль вазыйфаларга кертелгән очракта, әлеге вазыйфалар муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелми.";

2) кушымтада:
а) I кисәкнең 3 бүлегендә:
1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе*;";
2 пунктның өченче абзацында "тикшереп тору" сүзләрен "контроль-хисап" сүзенә алмаштырырга;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы.";
4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы.";
5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"контроль-хисап органы аппараты инспекторы.";
түбәндәге эчтәлекле сноска өстәргә:
"* Контроль-хисап органы рәисеннән гайре.";
б) II кисәкнең 7 бүлегендә:
1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Җирле үзидарәнең башка органы Җитәкчесе**;";
2 пунктның алтынчы абзацында "тикшереп тору" сүзләрен "контроль-хисап" сүзенә алмаштырырга;
3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы.";
4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы.";
5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"контроль-хисап органы аппараты инспекторы.";
түбәндәге эчтәлекле сноска өстәргә:
"** Контроль-хисап органы рәисеннән гайре.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында" 2008 елның 26 декабрендәге 135-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (V өлеш); 2011, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктның ундүртенче абзацында "контроль" сүзен "контроль-хисап" сүзенә алмаштырырга;

2) 12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аппаратының баш инспекторы;";

3) 14 пунктта:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:
"муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аппаратының әйдәүче инспекторы;";
б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга;

4) 15 пунктта:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

"муниципаль районның, шәһәр округының контроль-хисап органы аппараты инспекторы;";

б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 14 июле
№ 51-ТРЗ